КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 апрель г.Казань № 402

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2017 ел, 15 декабрь, 996 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 26 февраль, 110 нчы; 2018 ел, 7 май, 327 нче; 2018 ел, 30 июль, 614 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1288 нче; 2019 ел, 23 апрель, 329 нчы; 2019 ел, 18 декабрь, 1165 нче; 2020 ел, 11 февраль, 87 нче; 2020 ел, 15 май, 392 нче; 2020 ел, 8 август, 666 нчы; 2021 ел, 17 июнь, 467 нче; 2021 ел, 11 август, 700 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 817 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, 1140 нчы; 2021 ел, 9 декабрь, 1209 нчы, 2022 ел, 7 март, 202 нче, 2022 ел, 17 март, 244 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның өченче абзацында «, шулай ук су биологик ресурсларын» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.2.1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төбәк әһәмиятендәге махсус сакланала торган табигать территорияләрен булдыру, төбәк әһәмиятендәге махсус сакланала торган табигать территорияләрен махсус саклау режимының бурычлары һәм үзенчәлекләре турында»;

түбәндәге эчтәлекле 4.2.2$^{1}$ пунктча өстәргә:

«4.2.2$^{1}$. «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон белән каралган очракларда һәм

тәртиптә Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә документларны (аларда булган белешмәләрне) җибәрә, шул исәптән төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигый территория чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында, төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территориясе турындагы нигезләмәне раслау һәм әлеге нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында, шулай ук көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән расланган XML-документлар форматында төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигый территориянең сак зонасы чикләрен билгеләү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару турында белешмәләрне Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына кертүгә юнәлдерелгән гамәлләрне гамәлгә ашыра.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 941 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 30 декабрь, 1349 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Махсус саклана торган табигать территорияләрен саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) турындагы нигезләмәгә, 6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«6.1. Төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төп күрсәткече булып төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигать территорияләрендә, төбәк әһәмиятендәге махсус саклана торган табигый территорияләр чикләрендә дәвалау-савыктыру урыннарында һәм курортларда урнашкан урманнарга, шул исәптән урман утыртмаларына яисә урман утыртмаларына кертелмәгән агачларга, куакларга һәм лианаларга китерелгән зыян күләме, млн.сум.

Төп күрсәткечнең максатчан әһәмияте кабул ителә ≤ 10,0 млн.сум.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин